**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**"18" сентябрь 2018 ел** **№ 83**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү һәм үткәрү турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Кама Тамагы районы Уразлы авыл җирлеге Уставының 15 статьясы нигезендә, Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге башлыгының 2018 елның 22 сентябрендәге 06 номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары, Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 сентябрендәге 82 номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары нигезендә Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге Советы **карар кабул итте**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча 2018 елның 18 ноябренә җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:
"Сез 2019 елда Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән 500 сум үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны киләсе эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:
**- Жирлек территорияси эчендә чисталыкны өештрыү**;
*** Күмү урыннарын карап тору;**

*** Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**
- Уразлы, Сатлыган һәм Кече Карамал авылындагы юлларны ремонтлау
3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерү:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Уразлы авылы, Тынычлык урамы, 7;
2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кече Карамал авылы, Кече урамы, 11, шулай ук «Волжские зори» («Идел таннары») газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

“Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Уразлы авыл җирлеге”
башлыгы, “Татарстан
Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы
Уразлы авыл җирлеге”
Советы рәисе М.Г.Хәмидуллин